

Мордовиядә татар милләтле халык 50 менгә якын яши. Алар республикабыз жирләре буенча чәчелеп – я коньякта, я кончыгышта чәчелеп авылы-авылы белән утырган. Мордовия Республикасынын Зубово-Поляна районында оч татар авылы бар: Татарский Лундан, Горенка, Кочетовка. Кочетовка, аны яратып жирле халык Чатока диләр. Ул Лундан елгасы буена урнашкан.

1869нчы елда язылган «Пенза губернасынын торак урыннары исемлегендә» («Списке населенных мест Пензенской губернии») Кочетовка - Керенский оязенен 54 йортлы авыл. Анын исеме-  антропоним: Россия Дәvләтенен коньяк-кончыгыш чигендәге служилый мордвиннар (Кичатово) торак пунктнын хужалары булган. «1692 елгы Керенский унлыгы»ннан мордвин Петрушка Кочатовнын улы Смирка һәм оныгы Сайгановка белән чик буе хезмәтенә ия булуы, Кочатовлар яна урынга яшәргә кvченгәч, аларнын жирләре темников ягы хезмәтле (служивые) татарларына кvчкәне язылган. Темник татарлары элеккеге Кочатовлар дачасы исемен саклап калганнар, дип язылган документта (57, 470).
Зубово-Поляна районы Кочетовка авылы Горенка авылы администрациясе ка рамагында. Аны житәкли Альбина Юнир кызы Телякова.



Кыш - арбанны, жәй - ча- нанны әзерлә, дигәндәй без кыш коне Кочетовкалылар су

белән тәэмин итv проблемаларын кvтәрергә булдык. Биредә кыш коне су башнялары туна һәм халык бер тамчы суга мохтаж булып тора. XXI гасырда мондый кvренешләрне кvрергә читен; сусыз бер кон яшәве дә авыр. Авыл халкы акча жыеп, кем кул коче ярдәмендә, мә- сәлән Куняшев Рафик Арифулла улы, Немешев Амаль Хәйдәр улы, Равиль Жиханша улы Куняшев vз кочләре бе- лән ремонт ясыйлар; аларга зур рәхмәт. Әмма мондый зур эшне хокvмәтсез башкарып чыгып буламы сон?
Башняга зур ремонт кирәк. Кочетовка авылы халкы авыл администрациясенә, Зубово-Поляна районы житәкчеләренә, анын судына; Госуслуги порталына, Мордовия житәкчесе кайнар линиясенә морәжәгать иткәннәр, ә йок һаман бер ук урында. Хатларга жавапларны Авыл администрациясенә юллыйлар: бу ул башкарып чыга торган эшмени!
Алда тагы кыш котә. Кочетовка авылы халкы исеменннән Наилә Ворошилова белән Диляра Юсупова, мин ВКонтакте сайтына кергәч, «Юлдаш»та бу проблеманы кvтәреп язуымны сорадылар; бәлки кем булса да ишетер, ярдәм итәр дип ометләнәләр. Бәлки Кочетовкада киләсе кыш су булыр?..

**Наилә НАСЫРОВА**